Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

**2023 елның 04 сентябреннән** **№ 90**

Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советының «Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлегенең муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Кама Тамагы муниципаль районы һәм бу мәгълүматны бастыру өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү» 2015 елның 20 мартындагы 117 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Банклар һәм банк эшчәнлеге турында «Федераль законның 26 статьясына һәм «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында «Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2022елның 18 июлендәге 472 номерлы Указына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советының «Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны бирү тәртибе турында» 2015 елның 20 мартындагы 117 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.түбәндәге эчтәлекле 4.1 өлеш өстәргә:

«4.1. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр биргән зат акчаларны алуның законлылыгынраслый торган белешмәләрне «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә аларны юкка чыгару датасыннан 15 эш көне эчендә тапшыра.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Олы Карамалы авыл җирлеге Советы рәисе** Байдамшин Э.И.